| ГЛАВА ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 ноябрь,2024 Ябалак авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Бәрлебаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Бәрлебаш авылы,Вахитов урамы,2А йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегендә Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә:

2. 2024 елның 23 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Бәрлебаш төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Бәрлебаш авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясенә кергән Бәрлебаш авылыда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм 2025 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау ( шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер, СИП чыбыклары сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгын һәм күл тирәсен чабу);
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

4.Әлеге карарны Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.